ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

«15» ноябрь 2022 ел | № 285

Әгерҗе муниципаль районында җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокукны сату буенча ачык аукцион уздыру турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә булган җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану максатыннан, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11, 39.12 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Аукцион комиссиясе составын расларга (1 нче кушымта).
2. Торак пунктларның җирләре составыннан җир кишәрлеген сату буенча аукцион үткәрергә һәм җир кишәрлекләрен аукционга куярга.
3. Әгерҗе муниципаль районында аукционда җир кишәрлегенә хокук сату өчен куела торган җир кишәрлекләренең исемлеген, бәяләү бәясе күләмен, сату өчен куела торган җир кишәрлегенең бәясен арттыру күләмен («аукцион адымы») расларга (2 нче кушымта).
4. Торак пунктларның җирләре составыннан җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокукны сату буенча аукцион үткәрергә һәм җир кишәрлекләрен аукционга куярга.
5. Әгерҗе муниципаль районында аукционда җир кишәрлегенә аренда килешмәсе төзү хокукына сатуга куела торган җир кишәрлекләре исемлеген, бәя бирү бәясен күтәрү («аукцион адымы») күләмен (сатуга куела торган җир кишәрлегенең бәясен арттыру күләмен (3 нче кушымта)расларга.
6. Аукцион үткәрү һәм аның нәтиҗәләре турында мәгълүмати хәбәрне вакытлы матбугатта - «Әгерҗе хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җир кишәрлекләрен арендалау килешмәсе төзү хокукын сату буенча ачык аукцион үткәрү турында хәбәрне Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Россия Федерациясенең рәсми сайтында аукционнар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен (https://torgi.gov.ru/new)урнаштырырга.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы** **Р. Р. Шәрипов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 15.11.2022 елның 285
номерлы карарына 1 нче кушымта

**Аукцион комиссиясе составы**

1. Шәрипов Рөстәм Рәшитович-**комиссия рәисе**, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын башкаручы;

2. Поносов Эдуард Александрович – **комиссия рәисе урынбасары,** Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча);

**Комиссия әгъзалары:**

3. Лукшин Павел Алексеевич – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының контроль һәм исәпкә алу бүлеге башлыгы (килешү буенча);

4. Андреева Ирина Евгеньевна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе урынбасары (килешү буенча);

5. Заитова Аида Салиховна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисадый үсеш бүлеге башлыгы (килешү буенча).

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 15.11.2022 елның 285
номерлы карарына 2 нче кушымта

## Әгерҗе муниципаль районында аукционда җир кишәрлегенә хокук сату өчен куела торган җир кишәрлекләренең исемлеген, бәяләү бәясе күләмен, сату өчен куела торган җир кишәрлегенең бәясен арттыру күләме («аукцион адымы»)

| № | Җир кишәрлегенең урнашуы, мәйданы, кадастр номеры, аукцион үткәрү өчен нигез, капиталь төзелеш объектының рөхсәт ителгән максималь һәм (яки) минималь рөхсәт ителгән параметрлары турында мәгълүмат, капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэминат челтәрләренә тоташтыруның (технологик тоташтыруның) техник шартлары һәм аларның гамәлдә булу вакыты турында, тоташтыру өчен түләү (технологик тоташтыру)турында мәгълүмат | Рөхсәт ителгән куллану | Еллык аренда түләвенең башлангыч күләме, сум | Аукцион адымы (башлангыч бәянең 3% ,сум | Алдан биреп кую (башлангыч бәянең 100%), сум |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Әгерҗе шәһәре, К. Маркс урамы, ж/у 10Б, мәйданы 101 кв. м. кадастр номеры - 16:01:220223:580 | кибетләр | 139000 | 4170 | 139000 |

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 15.11.2022 елның 85
номерлы карарына 3 нче кушымта

**Әгерҗе муниципаль районында аукционда җир кишәрлегенә аренда килешмәсе төзү хокукына сатуга куела торган җир кишәрлекләре исемлеген, бәя бирү бәясен күтәрү («аукцион адымы») күләмен (сатуга куела торган җир кишәрлегенең бәясен арттыру күләмен**

| № | Җир кишәрлегенең урнашуы, мәйданы, кадастр номеры, аукцион үткәрү өчен нигез, капиталь төзелеш объектының рөхсәт ителгән максималь һәм (яки) минималь рөхсәт ителгән параметрлары турында мәгълүмат, капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэминат челтәрләренә тоташтыруның (технологик тоташтыруның) техник шартлары һәм аларның гамәлдә булу вакыты турында, тоташтыру өчен түләү (технологик тоташтыру)турында мәгълүмат | Рөхсәт ителгән куллану | Аренда срогы | Еллык аренда түләвенең башлангыч күләме, сум | Аукцион адымы (башлангыч бәянең 3% ,сум | Алдан биреп куюо (башлангыч бәянең 100%), сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 2 | Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Кадрәк авыл җирлеге, мәйданы 20179 кв. м. кадастр номеры - 16:01:170202:261 | терлекчелек | 1069,49 | 32,08 | 1069,49 | 1069,49 |